| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

28 октября 2024г. с.Шалты № 107

Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 17.10.2019 № 96 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 15.05.2024 ел, № 99-ФЗ Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 17.10.2019 № 96 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (17.04.2020 № 115, 18.12.2020 № 11, 06.06.2024 № 98 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8-нче статьяның 1-нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

28-нче статьяның 5-нче пунктының 2-нче абзацында «1-7 пунктлары» сүзләрен «1-7 һәм 9.2 пунктлары» сүзләре белән алмаштырырга;

42-нче статьяның 1-нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге 9.1) пунктчасы белән тулыландырырга:

«9.1) чит ил агенты статусын алуы;»;

51-нче статьяның 1-нче пунктының 5) пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«- «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.».

2. Әлеге карарны федераль закон нигезендә дәүләт теркәве өчен юстиция органына җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвеннән соң әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин